# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ "БОЛГАР ШӘҺӘРЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**№ 39-3** **«02»июль 2024 ел**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «региональ салымнар суммалары өлешендә бурыч түләүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган җирле салым суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http: //pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Болгар шәһәр Башкарма комитетына йөкләргә.

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.В. Мөхәммәтов